| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 186

Аерым категория затларның аларда катнашу хезмәт (вазыйфаи) вазыйфаларны үтәү белән бәйле протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралар белән бәйле бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында

2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы «Аерым категория затларның аларда катнашу хезмәт (вазыйфаи) вазыйфаларны үтәү белән бәйле протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралар белән бәйле бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү,сату һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында» Карарына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Кушымта итеп бирелә торган аерым категория затларның аларда катнашу хезмәт (вазыйфаи) вазыйфаларны үтәү белән бәйле протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралар белән бәйле бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы 27.02.2014 чыккан 206 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан аларның вазыйфаи хәле, хезмәт (вазыйфаи) вазыйфалар башкару белән бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге Карарны Интернет челтәренең мәгълүматый-телекоммуникацион «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р.Хәялиевка йөкләргә.

Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 23.09.2019 186 номерлы карарына Кушымта №1

**Аерым категория затларның аларда катнашу хезмәт (вазыйфаи) вазыйфаларны үтәү белән бәйле протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралар белән бәйле бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан аларның вазыйфаи хәле, хезмәт (вазыйфаи) вазыйфалар башкару белән бәйле рәвештә бүләк алу турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату һәм сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

«протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләк» - муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар, хезмәткәрләр тарафыннан физик (юридик) затлардан, протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралар кысаларында һәр катнашучыга күрсәтелгән чарада хезмәт вазыйфаларын башкару өчен бирелгән канцелярия кирәк-яракларыннан, бүләкләү сыйфатында бирелгән чәчәкләр һәм кыйммәтле бүләкләрдән кала бүләк бирү бүләк алучының вазыйфаи хәленә яки башкара торган вазыйфаи хезмәтләренә бәйле рәвештә бирелә торган бүләк;

«катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралар белән бәйле бүләк алу» - муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар, хезмәткәрләр тарафыннан шәхсән яки арадашчы аша физик (юридик) затлардан вазыйфаи регламент (вазыйфаи инструкция) белән бәйле вазыйфаларны үтәү, шулай ук күрсәтелгән затларның һөнәрм хезмәт эшчәнлеге үзенчәлекләрен билгели торган федераль законнар һәм башка норматив актлар белән билгеләнгән хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле очраклар.

3. Муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар, хезмәткәрләр катнашу хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралардан кала физик (юридик) затлардан вазыйфаи хәленә яки башкара торган вазыйфаи хезмәтләренә бәйле рәвештә бүләк алырга хокуклы түгел.

4. Муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар, хезмәткәрләр, эшчеләр әлеге нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чараларда бүләк алуның һәр очрагы турында күрсәтелгән затлар муниципаль хезмәт куя яки эшли торган муниципаль органга хәбәр итәргә тиеш.

5. Хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чараларда бүләк алу турында кушымта нигезендә төзелгән хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) бүләк алганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча вәкаләтле вазыйфаи затка (алга таба - вәкаләтле вазыйфаи зат)

хәбәр ителергә тиеш. Хәбәрнамәгә бүләк бәясен раслаучы документлар (булса), (касса чегы, товар чегы, бүләк өчен түләү турында башка документ) теркәлергә тиеш.

Бүләк хезмәт командировкасы вакыт алынса, хәбәрнамә зат командировка-дан кайтканнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән срокларда муниципаль вазыйфалар башкаручы затлар, хезмәткәрләр, эшчеләргә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында хәбәрнамә бирү мөмкин булмаса, хәбәрнамә сәбәп бетерелгәннән соң бер көн эчендә юллана.

6. Хәбәрнамә 2 нөсхәдә әзерләнә, берсе теркәү турында билге белән аны тапшырган затка кире кайтарыла, икенче нөсхәсе бухгалтерлык исәбе канунчылыгы нигезендә оештырылган муниципаль органга активлар килү һәм китү буенча комиссиягә (алга таба - комиссия) җибәрелә.

7. Бәясе документлар белән раслана һәм 3 мең сумнан артып китә торган яисә бәясе аны алган хезмәткәр, эшчегә билгеле булмаган бүләк вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла, ул аны тиешле теркәү журналында теркәлгәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул итү-тапшыру акты нигезендә ала.

8. Муниципаль вазыйфалар башкаручы зат тарафыннан алынган бүләк бәясе карамастан әлеге нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән тәртиптә саклауга тапшырыла.

9. Бүләкне кабул итү-тапшыру акты нигезендә тапшырганчы аны алган зат бүләкне югалту яки бозу өчен Россия Федерациясе канунчылыгы нигезендә җаваплы.

10. Россия Федерациясе канунчылыгы белән билгеләнгән тәртиптә бүләкне бухгалтерлык исәбенә алу максатында, аның бәясен билгеләү бүләкне исәпкә алу датасына базар бәясе нигезендә башкарыла. Базар бәясе турында мәгълүматлар документ белән раслана, документ беләнраслау мөмкин булмаганда- эксперт юлы белән. Бәясе 3 мең сумнан артмаса, бүләк кабул итү-тапшыру акты нигезендә аны тапшырган затка кире кайтарыла.

11. Вәкаләтле вазыйфаи зат бухгалтерлык исәбенә алынган бәясе 3 мең сумнан арткан бүләкне билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек реестрына ала.

12. Муниципаль вазыйфалар башкаручы бүләкне тапшырган затлар, бүләкне тапшырганнан соң ике айдан да соңга калмыйча эш бирүче вәкиленә тиешле гариза язып сатып ала алалар.

13. Вәкаләтле вазыйфаи зат әлеге нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза кергәннән соң 3 ай эчендә бүләкнең бәясен билгеләүне оештыра һәм гариза биргән затка бәяләү нәтиҗәләрен язмача хәбәр итә, шуннан соң бер ай эчендә мөрәҗәгать итүче бүләкне сатып ала яки баш тарта.

14. Аңа карата әлеге нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза кермә-гән бүләк муниципаль орган тарафыннан комиссиянең бүләкне максатчан куллану турында бәяләмәсен истә тотып муниципаль орган эшчәнлеген тәэмин итү өчен куллана ала.

15. Бүләкне куллану максатчан булмаган очракта муниципаль орган җитәкчесе Россия Федерациясе канунчылыгы белән билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле муниципаль орган тарафыннан сатулар оештырып бүләкне сату һәм сату өчен аның бәясен билгеләү турында карар кабул итә.

16. Әлеге нигезләмәнең 13 һәм 15 пунктларында каралганча сату өчен бүләк бәясен билгеләү бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе канунчылыгы белән билгеләнгән тәртиптә бәяләү эшчәнлеге субъектлары тарафыннан башкарыла.

17. Әгәр бүләк сатып алынмаса һәм сатылмаса, муниципаль орган җитәкчесе тарафыннан кабат аны сату, я булмаса хәйрячелек оешмасы балансына бушлай бирү, яисә Россия Федерациясе канунчылыгы белән билгеләнгән тәртиптә аны юкка чыгару турында карар кабул ителә.

18. Бүләк сатудан кергән акчалар Россия Федерациясе бюджет канунчылыгы белән билгеләнгән тәртиптә Кайбыч муниципаль районы бюджетына кертелә.

Аерым категория затларның аларда катнашу хезмәт
(вазыйфаи) вазыйфаларны үтәү белән бәйле
протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка
рәсми чаралар белән бәйле бүләк алу турында хәбәр
итү , бүләкне тапшыру һәм бәяләү,сату һәм сатудан
кергән акчаларны күчерү турында Нигезләмәгә Кушымта

Бүләк алу турында хәбәрнамә

____________________________________________
(Муниципаль органның вәкаләтле заты вазыйфасы)
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
(ф.и.а.и, башкара торган вазыйфасы)

«___» _________20__е. бүләк алу турында хәбәрнамә.

___________________________________________________________________
(протокол чаралар, хезмәт командировкалары, башка рәсми чаралар
___________________________________________________________________
исеме, үткәрелү урыны һәм датасы)

бүләк алуым турында хәбәр итәм.

| Бүләк исеме | Бүләк характеристикасы, тасвирламасы | Предметлар саны | Бәясе, сумнарда* |
|---|---|---|---|

1.
2.
3.
Барысы

Кушымта: _______________________________________ ______ биттә.
(документ атамасы)

Хәбәрнамәне тапшыручы зат
_____________ ________________________ «__» _______20__ел
(имза) (расшифровкасы)

Хәбәрнамәне кабул итүче
зат _____________ ________________________ «__» _______20__ел
(имза) (расшифровкасы)

Хәбәрнамәләр теркәү журналында теркәү номеры
____________ «___» _________20__ел

*Бүләк бәясенраслаучы документлар булса тутырыла.